РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» ноябрь 2022 ел Олы Кайбыч ав. №155

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 01 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән күрсәтелгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 13 апрелендәге 168 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19, 20, 21 пунктчалар өстәргә:

«19) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү;

20) муниципаль милекне формалаштыру, идарә итү һәм мондый милек белән эш итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милекне формалаштыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукларны да кертеп) үтәүне тикшереп тору;

21) муниципаль эчке һәм тышкы бурычның торышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч

муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин